АШЫГУ ХӘЕРЛЕМЕ?

22 марттан БДИны алдан бирү этабы башлана

> 2

ҖЫРЛАП СӨЕНСЕННӘР!

«Балачак җыры» бәйгесе сүз һәм көй тәмен белүче буын тәрбияли

> 3

БӘХЕТ УЛ – ...

Халыкара бәхет көнендә аның төсен һәм тәмен ачыкладык

> 4

МАНАРАЛЫ, АЙЛЫ

Гомәр Гарифуллин кошларны матур оя-йортлар ясап каршы ала

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 35 (29195) | Чәршәмбе | 20 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БАШТА – ТАВЫШ, АННАРЫ – КӘЕФ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Актуаль тема

Соңгы тугыз елда Татарстанда 400гә якын иҗтимагый киңлекне яңартканнар. Бу эшкә алынганнан бирле республикада парклар, скверлар һәм яр буйларын төзекләндерүгә 24 миллиард сум акча тотылган. Ә ишегалларын тәртипкә китерүгә быел гына да 10 миллиард сум акча сарыф итәчәкләр. Агымдагы елга эш билгеле. Ә менә киләсе елда төзекләндереләчәк иҗтимагый киңлекләр өчен инде хәзер үк тавыш бирәсе.

Асфальтлы-эскәмияле ишегаллары, балалар мәйданчыклары, спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлыклары булган парклар һәм скверларга тәмам ияләшеп беттек. Бүген Казан, Чаллы кебек зур шәһәрләрдә генә түгел, хәтта авылларда да заманча ял мәйданнары гадәти күренешкә әверелеп бара.

– Киләсе елда Татарстанда иҗтимагый киңлекләрне үстерү программасын тормышка ашыра башлаганга ун ел була, – диде «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрының беренче урынбасары Алексей Фролов. – 2015–2023 елларда 398 парк, сквер һәм яр буе тәртипкә китерелде. Шул исәптән 225 иҗтимагый киңлектә төзекләндерү эшләре «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты кысасында башкарылды. Бу эшкә барлыгы 23,9 миллиард сум акча тотылды.

Әлеге эш алга таба да дәвам иттереләчәк. Шунысы сөенечле: кайсы иҗтимагый киңлекне яңартырга кирәк икәнен республикада яшәүчеләр белән бергәләп хәл итәләр.

– Татарстанда 2025 елда төзекләндереләчәк иҗтимагый киңлекләр өчен тавыш бирү башланды, – диде Алексей Фролов. – Тавыш бирү 30 апрельгә кадәр Дәүләт хезмәтләре порталында дәвам итәчәк. Бу эштә республикада яшәүче, 14 яше тулган һәркем катнаша ала. Киләсе елда төзекләндерү өчен 274 иҗтимагый киңлек тәкъдим ителгән. Без республиканың барлык районнарын да колачладык.

Билгеле булганча, иҗтимагый киңлекләр өчен тавыш бирү тәкъдиме иң элек Татарстанда туды. Соңрак аны ил күләмендә дә җәелдерделәр. Былтыр республикада тавыш бирүдә 363 меңнән артык кеше катнашкан булган.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов телеграм-каналында республикада яшәүчеләрне иҗтимагый киңлекләр өчен тавыш бирүдә катнашырга чакырды. «Татарстанда матур парклар һәм уңайлы ял итү урыннары күбрәк булсын! Катнашмый калма, үз фикереңне әйт!» – дип язган ул.

ИҖТИМАГЫЙ КИҢЛЕКЛӘР ӨЧЕН НИЧЕК ТАВЫШ БИРЕРГӘ?

✓Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталына, «Услуги РТ» мобиль кушымтасына яки gorodsreda.tatar.ru сайтына керергә;
✓ЕСИА яки телефон номеры буенча тиешле вәкаләтне алырга;
✓«Опросы жителей» бүлегендә тавыш бирергә.

– Республикада яшәүче бер кеше – бер тавыш, – дип тә искәртте Татарстан шәһәрләрен үстерү институты җитәкчесе Наилә Зиннәтуллина. – Үзең яшәгән җирлек белән генә чикләнү мәҗбүри түгел. Мәсәлән, Казанда яшәүчеләр республиканың теге яки бу районында урнашкан иҗтимагый киңлек өчен дә тавыш бирә ала.

Татарстанда программа кысасында хастаханә тирәләрен төзекләндерү эшенә дә алынмакчылар. «Тәүге тапкыр Әлмәтнең хастаханә шәһәрчеген үзгәртеп корырга ниятлибез. Ни кызганыч, әлегә биредә сәламәтләнү өчен уңайлы мохит юк. Үзегез уйлап карагыз: хастаханәгә көненә 2 меңләп кеше килә. Зур паркларда да бу кадәр йөрүче юк», – диде Наилә Зиннәтуллина. Тавыш бирү барышында республиканың 11 районындагы үзәк хастаханә территорияләрен төзекләндерү өчен тәкъдим иткәннәр.

Сүз уңаеннан, тавыш бирүдә катнашучылар берьюлы ике куянның койрыгын тотачак. Тавыш бирү барышында парклар, скверлар һәм яр буйлары өчен генә түгел, ә «Безнең ишегалды» программасы кысасында яңарту таләп ителгән ишегалдын да сайларга мөмкин. Соңгысы Татарстанда биш елдан бирле гамәлдә. Ул алга таба да дәвам иттереләчәк. Бу хакта Алексей Фролов әйтте.

– Бу эшкә тотынганда программа биш елга исәпләнәчәк дип фаразладык. Тик аңлыйбыз: яңарту таләп ителгән барлык ишегалларын төзекләндереп бетерү өчен биш ел гына җитмәячәк. Шуңа күрә «Безнең ишегалды» программасы алга таба да дәвам иттереләчәк. Быел аны тормышка ашыруга бүлеп бирелгән акча күләме дә 1 миллиард сумга арттырылды. Беренче чиратта, бу – төзелеш материаллары кыйммәтләнүгә бәйле, – диде министрның беренче урынбасары.

2020–2023 елларда республикада әлеге программа кысасында 4339 ишегалдын ялт иттергәннәр. Биш ел эчендә 34 миллиард сумлык эш башкарылган. «Быел тагын 833 ишегалдын төзекләндерергә ниятлибез. Биредә әзерлек эшләре башланды инде. Кар эреп беткәнне генә көтәбез, – диде Алексей Фролов. – Республикадагы тагын 1550 йорт яны территориясен тәртипкә китерергә кирәк. Барлык эшләрне алдагы ике елда төгәлләргә ниятлибез».

Ахыры 2 нче биттә >

Казнаны баеталар

Быел ике айда – гыйнвар һәм февральдә министрлыклар халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтүдән республика казнасына барлыгы 1,5 миллиард сумнан артыграк акча керткән. Финанс министрлыгы бастырган саннарга караганда, Сәламәтлек саклау министрлыгы барыннан да күбрәк – 922,2 миллион сум акча эшләгән. Ә менә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы – соңгы урында. Ул узган елда да беренче ике айда казнага бер тиен дә кертмәгән булган.

Мәгариф һәм фән, Мәдәният министрлыклары икесе бергә бюджетка 600 миллион сум чамасы акча күчергән. Урман хуҗалыгы министрлыгы – 80,2 миллион, Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы – 49,5 миллион сум, Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы исә 629 мең сум гына акча эшләгән.

Ел азагына кадәр министрлыклар казнага барлыгы 12,2 миллиард сум акча кертергә тиеш. Бу – узган елдагыдан 1 миллиард сумга күбрәк.

Качып калып булмый

Татарстан приставлары ел башыннан бирле алименттан качып йөрүчеләрдән 215 миллион сумлык бурычын түләткән. Суд приставлары Баш идарәсе матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, бу узган елның шушы ук чорындагыга караганда 52 миллион сумга күбрәк.

Приставлар искәртеп үткәнчә, бурычын түләмәүчеләргә карата мөлкәтен алу, әҗәтен хезмәт хакыннан тотып калу, күчемсез милекне теркәүне тыю, чит илгә чыгармау кебек бик күп чаралар кулланыла.

Моннан тыш мондый ваемсызлар машина йөртү хокукыннан мәхрүм ителергә, шулай ук административ, хәтта җинаять җаваплылыгына тартылырга мөмкин.

fssp.gov.ru

Кәгазь җыялар

Республикада 16 апрельдән «Макулатура тапшыр – агачны коткар» экомарафоны башлана. Акция елына ике тапкыр үткәрелә. Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы хәбәр итүенчә, ул Татарстан районнары һәм шәһәрләре арасында ярыш рәвешендә уздырыла. Төп бурычы – халыкта табигать байлыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү, калдыкларны эшкәртү өлкәсен үстерүгә өлеш кертү.

Марафонда барлык уку йортлары, иҗтимагый оешмалар, предприятие, компанияләр һәм башка оешмалар катнаша ала. Моның өчен кимендә 300 кг кәгазь җыеп, акциянең рәсми сайтында (Сдавайбумагу.рф яки www.Sdai-Bumagu.com) гариза калдырырга кирәк. Ә инде 300 кг кәгазь җыя алмаса да, үзеннән азмы-күпме өлеш кертергә теләүчеләр эш урынына яки якындагы уку йортына мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Акциядә катнашучыларның барысына да – Рәхмәт хатлары, ә иң күп кәгазь тапшыручыларга акчалата премияләр тапшырылачак. Бер яки берничә оешма бер ноктада 1 тоннадан күбрәк авырлыкта макулатура җыйган очракта акчалата бүләк бирелә.

Мартта – шарт

Бу атнада республикада һава температурасы «уйнаячак»: көндез җылы, ә төнлә –18 градуска кадәр салкын булачак. Аз гына кар явачак.

Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, пәнҗешәмбе – 21 мартта явым-төшемсез болытлы һава көтелә. Көндез 0…+5, төнлә –7…–13, урыны белән –18 градус.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга – 22 һәм шимбә – 23 мартта һава торышы үзгәрмәячәк. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +1…+6 градус күрсәтәчәк. Төнге сәгатьләрдә –6…–11 градуска кадәр төшәчәк.

Сак бул!

Яшен тизлегендә тарала

Казанның 18 нче номерлы мәктәбендә кызамык ачыкланган! Узган атна уртасында республикада әнә шундый хәбәр таралды. Баштарак бу чирне бер балада тапсалар, күп тә үтми аларның саны бишкә җитте.

Сан

Ел башыннан бирле республикада кызамык йоктыруның 119 очрагы теркәлгән. Бу алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда 39,6 тапкыр (!) күбрәк. Узган ел Татарстанда ел дәвамында 146 кеше кызамык йоктырган булган.

Бу юлларны язганда Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе мәктәптә барлыгы 12 кешедә кызамык ачыклануын хәбәр итте. Шуларның берсе – укытучы.

Кызамык беренче сыйныф укучыларында табылган. Аларның барысы да кызамыкка каршы прививка ясатмаган булган. Мәктәптә мондый вакцинадан баш тартучыларның гомуми саны – 116. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта кызамык йоктырган укучылар укытучылары белән бергә инфекцияле авырулар хастаханәсендә дәвалана.

– Балаларның гомеренә куркыныч янамый, алар савыгуга таба бара. Эпидемик күрсәткечләр буенча кызамыкка каршы прививка ясала. Вакцина җитәрлек, алар барлык дәвалау оешмаларында да бар, – дип белдерделәр «ВТ» хәбәрчесенә министрлыкның матбугат хезмәтендә.

Хәзерге вакытта 18 нче мәктәптә дезинфекция үткәрелгән, уку дәвам итә. Әмма дәресләргә кызамыкка каршы прививка ясаткан укучыларны гына кертәләр. Кызамык белән авырган кеше бу чиргә каршы иммунитеты булмаган 100 кешенең 95енә тиз арада чир йоктыра ала.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш инфекционисты Халит Хәертынов сүзләренә караганда, кызамык гадәти ОРВИ кебек башлана. Температура күтәрелә, томау төшә, ютәл борчый.

– Авыруның бишенче-алтынчы көненә вирус йоткылыкның лайлалы тышчасы аша канга үтеп керә, шул рәвешле бөтен организмга тарала. Нәтиҗәдә тәнгә тимгелләр чыга. Ул башта биткә чыга, аннары акрынлап корсакка, аякларга тарала, – ди Баш инфекционист.

11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ Азизова сүзләренә караганда, кызамыкның нәтиҗәләре тагын да аяныччрак.

– Кызамык белән авырганнан соң, өлкәннәрдә пневмония башланырга мөмкин. Кызамык аркасында баланың баш мие тулысынча ялкынсынырга (панэнцефалит) мөмкин. Иң куркынычы шул: әлеге чир бала кызамык белән авырып терелгәннән соң биш еллап вакыт узгач кына пәйда була. Бала начар укый, баш авыртудан зарлана башлый. Авыру торган саен көчәя генә. Ата-ана эшнең нидә икәнен аңлый алмыйча тилмерә. Ахыр чиктә, бала инвалид ук калырга мөмкин. Ул нәкъ инсульт кичергән кеше кебек хәрәкәтләнә, сөйләшә алмый башлый, башы эшләми, – ди табиб.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

2024 гаилә елы

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА, язучы:

Гаилә ул – кешенең матди дә, рухи дә таянычы, бәхетнең ни икәнен тояр җирлеге. Иң олы куанычлары, иң тирән борчулары. Җир өстендәге мәхәббәт дигән хисне сакларга, кадерләргә өйрәтү үзәге. Гаиләдәге тынычлык серләренә килсәк, иң беренче сүзнең үскәнен, чәчәк атканын белеп яшәү мөһим. Вакытында дәшми калу да яхшы.

РОССИЯДӘ – АВЫЛЛАР

ГОМУМИ САН: 153 МЕҢ



* Халык санын алу нәтиҗәләре буенча

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ХӘФТӘР СУГЫШ СУКМАГЫНА ЧЫГА

Планетада Гражданнар сугышы барган илләр саны кимеми. Туплар атмаган, кешеләр кырылмаган бер генә көн дә юк. Суданда сәяси кризисның хәрби конфликтка әверелүенә инде елга якын вакыт үтте. Сугыш 2023 елның апрелендә башланган иде. Анда ике генерал – Хөкүмәт башлыгы Габдел-Фаттах әль-Борхан һәм аның урынбасары Мөхәммәд Хамдан Дагло хакимлекне бүлешә алмый. Илдә барган суеш 5 миллион суданлыны чит илләргә качарга мәҗбүр итте. Суданның финанс министры 2023 елда икътисадның 40 процентка түбәнәюен, быел тагын 28 процентлык түнтәрелеш көтелүен әйтте. Болай да барлык эчке тулай продукты 26 миллиард доллар гына тәшкил иткән илдә ачлык хөкем сөрә. Күз алдыгызга китерегез: үткән ел Россиядә Пригожин фетнәсе туктамый җәелгән булса, бездә нинди хәлләр уйналган булыр иде. Сүз уңаеннан искәртик: «Вагнер» – Пригожинның хосусый хәрби компаниясе Дагло солдатларын сугышырга өйрәтте дә инде. Күптән түгел Путин үзенең бер чыгышында искә алды бу хакта: Африкада барган хәлләргә рәсми Кремльнең катнашы булмавын, астан ут йөртүче көчнең «Вагнер» булуын әйтте. Судандагы хәлләрне кыска һәм өстән-өстән генә тасвирласак, шундый картина туа: илнең рәсми армиясе белән Хөкүмәте бар һәм Тиз ярдәм итү көчләре дип аталган коралды төркем хәрәкәт итә. Башында 48 яшьлек Дагло торган Тиз ярдәм итү көчләре Хөкүмәт армиясе белән конфликтка керде дә башланды инде хәлләр. Судан – болай да соңгы еллар тарихы кан коешлардан торган ил, хәзер аның бөтенләй асты-өскә килде. Генералларның ни бүлешә алмаулары турындагы теманың нечкәлекләренә кагылып тормыйбыз, чөнки ул зур сәясәт коридорларына илтә һәм Суданнан читтә булган йогынтылы көчләрнең мәнфәгатенә кагыла. Бер нәрсәне генә искәртик: фетнәче Дагло белән икенче бер гыйсъянчы фельдмаршал Хәлифә Хәфтәр арасында дуслык һәм хезмәттәшлек хөкем сөрә. Соңгысы – Каддафи үлеменнән соң фетнә һәм болганчыклык хөкем сөргән Ливия каһарманы. Ливиядәге вазгыять турында алдагы елларда без бер генә тапкыр язмадык. Бүген анда ике хакимият, ике тәхет. Каддафидан соң көнбатышлылар һәм БМО яклавы астында төзелгән Милли килешү хөкүмәте һәм Ливия милли армиясенең башкомандующие дип саналган Хәфтәр арасында озак еллар хәрби конфликт барды. Соңгы елларда килешүгә ирешелеп, конфликт тынган һәм ил икегә бүленгән хәлдә яши иде. 82 яшьлек Хәфтәр соңгы көннәрдә: «Сәяси сабырлыгыбыз төкәнде, хәлиткеч хәрәкәткә әзербез», – дип белдерде. Димәк, яңадан ил башкаласы Триполига хәрби походка әзерләнә. Ул Триполины бер тапкыр ала язган иде инде, рәсми хөкүмәтне Төркия ярдәмгә килеп коткарды. Нефтькә бай бу илдә күп төрле көчләр мәнфәгате үзара кисешә, шул кисешү нокталарында яңа киеренкелек барлыкка килде.

Россиядә

ЛОКОМОТИВЛАР ТУЗА, ЛИФТЛАР ДА...

Торак-коммуналь хуҗалыктагы быелгы кышкы масштаблы катастрофа халык хуҗалыгының башка тармакларында да кабатланырга мөмкин. Рәсми отчетлар шуны искәртә. Үткән атнада мәгълүмат кырында Россия тимер юллары ачык акционерлык җәмгыятенең (ОАО РЖД) рәсми хисабы игълан ителде. Аннан шул күренә: локомотивларга сервис хезмәте күрсәтү катлауланган һәм үтәп булмаслык бурыч чигенә якынаеп килә. 2023 елда локомотивларга ремонт ясалмау сәбәпле туктап калган поездлар саны ике тапкыр арткан. Сәбәбе ялкаулыкта түгел, билгеле. Комплектлаучы детальләр җитешми. Иң кирәкле детальләрне җитештерүне җайга салу омтылышы бар икән үзе, әмма сүз арба тәгәрмәче турында гына бармый. Катлаулы технологияләр таләп ителгән процесс сорала. Импортны алыштыру алай бик җиңел эш түгел. 42,6 мең локомотив ремонт сорап туктап калган икән. Санга карасак, ашыгыч рәвештә катлаулы детальләрне серияле җитештерүче яңа заводлар төзергә кирәк. Бу исә мөмкин эш түгел. Масштаблы инвестицияләр сорый, технологик җиһазлар җитештерүне җайга саласы бар, кадрлар әзерләү таләп ителә. Акчасы табылган очракта да, елларга сузыла торган эш. Пассажир самолетларын серияләп җитештерүне җайга салып булмый әле монда. Үрнәк моделе бар, электән калган авиация заводлары да торгызылып килә, кайчандыр булган совет тәҗрибәсе дә онытылып ук бетмәгән, әмма конвейерларның хәрәкәткә килү сәгате гел артка күчерелә.

Төбәкләрне үстерү фонды да күңелсез хәбәрләр ирештерә. Илдә 78500 лифтны алыштырырга кирәк. Техник регламент шуны таләп итә. 56840 лифтның инде куллану срогы чыккан, тагын 21620 лифтныкы 2025 елга кадәр чыгачак. Бу кадәр техниканы алыштыру өчен төбәкләрнең ресурслары чикләнгән, диләр фондта. Димәк, я җәяү йөрергә, я тәвәккәлләп, срогы чыкан лифтларда күтәрелергә туры киләчәк. Белгечләр, аның кадәр лифтны алыштыру реаль бурыч түгел, диләр.

Нинди генә бурыч куелмасын, аңа бюджеттан акча табу таләп ителә. Бюджет исә резин түгел, болай да дефицитта утыра. Әле Юлламада вәгъдә ителгән проектлар өчен дә триллионлаган сум акча кирәк. Салым йөге арттырылачак, бу хакта Путин әйтте инде.

БӘХЕТЛЕЛӘР ШӘҺӘРЕ

Халык саны – 7800, уртача яшь – 31, барлыкка килүенә – 8 ел. Кирәк җиргә робот-такси илтеп куя, ризыкны робот-курьер китерә. Аңлагансыздыр инде, сүзебез Россиянең иң яшь һәм иң заманча шәһәре – Иннополис турында.

Хөкүмәт йортында шәһәр җитәкчелеге узган елга нәтиҗә ясады һәм киләчәккә планнар билгеләде.

– Иннополис актив һәм эзлекле үсүен дәвам итә, – диде Татарстанның вице-премьеры Роман Шәйхетдинов. – Бер ай элек шәһәрдә пилотсыз авиация системасын эксплуатацияләү эше тәмамланды. Тиздән ул шәһәрдә авиация эшләрен башкара, йөк ташый, аэрофотога төшерә, торбаүткәргечләрне һәм башка инфраструктура объектларын тикшерә алачак.

Иннополиска саллы гына инвестицияләр дә килә. Роман Шәйхетдинов сүзләренчә, бүген биредә 22 млрд сумлык инвестиция проектлары гамәлгә ашырыла.

Биредә даими рәвештә 7800 кеше яши. Аларның уртача яше – 31. Шәһәр мэры Руслан Шәгалиев сүзләренә караганда, халык саны ел ахырына 1,5 меңгә кадәр артыр дип көтелә. Шәһәрдә яшәүче һәр өченче кеше – йә галим, йә IT тармак белгече. Иң бәхетле кешеләр дә Иннополиста яши икән. Бәхет күрсәткече биредә 86ны (!) тәшкил итә. (Россия буенча ул – 68.)

Узган ел шактый эш башкарылган. Төзекләндерүне алсак, җәяүлеләр өчен юл күрсәткечләре, яңа тукталыш павильоны, ишегалларының берсендә балалар мәйданчыгы барлыкка килгән. Шәһәр буенча 8 пилотсыз такси йөри, халык робот-таксины көненә уртача 88 тапкыр чакыра. Ризыкны 15 робот-курьер китерә, узган елда алар 58 меңгә якын заказ үтәгән.

2024–2025 елларга Иннополиста аэрологистика һәм шәһәрнең цифрлы дубликатын эшләп бетерергә ниятлиләр. Быел биредә күптән көтелгән беренче кунакханә дә үз ишекләрен ачачак. Хәзерге вакытта бина эчендә бизәү эшләре алып барыла. Шулай ук ел ахырына кадәр Иннополиста 62 мең квадрат метр мәйданлы ике яңа технопарк төзелеше тәмамланачак.

Иннополис – саннарда

- **1239** – студент;
- **1348** – бала;
- **1854** – фатирда яшәүчеләр:
- **624** – компанияләр һәм ИП;
- **14980** – автобус рейслары.

Әмма барысы да ал да гөл генә түгел. Шәһәр һәм резидент компанияләр яңа кешеләрне җәлеп итә, әмма аларны урнаштырырга урын юк. Торакка кытлык кичерәбез, ди Руслан Шәгалиев. Беренчел базарда торак бәясе 1 квадрат метры өчен 180 мең сумнан башлана. Сүз югары сыйфатлы йортлар турында бара.

– Узган ел безнең өчен бай һәм нәтиҗәле булды, – дип башлады сүзен «Иннополис» махсус икътисадый зонасының генераль директоры Ренат Хәлимов.

Саннар теле белән әйткәндә, биредә 333 компания эшчәнлек алып бара – 130 резидент, 59 партнер һәм 144 стартап. Узган ел инвестицияләр күләме 36,4 млрд сум тәшкил иткән, компанияләрнең табышы – 49,7 млрд сум.

Быел «Иннопарк» технопаркында гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү системасын эшләтеп җибәрү планлаштырыла.

– Югары технологияле система Татарстанда да, Россиядә дә бик кирәкле булачак, – диде Ренат Хәлимов.

«Акыллы башлар»ны әзерләүче университетта исә барлыгы 1239 студент укый. Узган ел югары уку йортына дөньяның 150 иленнән (!) 11 меңнән артык гариза килгән. Бу алдагы ел белән чагыштырганда 2 меңгә күбрәк.

– Узган елны финанс яктан уңышлы дип саныйбыз. Бу мөһим, чөнки безнең университет дәүләт вузы түгел, – диде университет директоры Кирилл Семенихин.

Ләйсән САФИНА

Башта – тавыш, аннары – кәеф

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстанда 2020 елдан бирле тормышка ашырылучы «Безнең ишегалды» программасы кысасында 2 мең чакрымнан да артык озынлыкта җәяүлеләр юлы салганнар инде. «Бу – Казаннан Калининградка кадәр юл дигән сүз», – диде проектның кураторы Арина Петрова. Татарстанның 13 районында программага кергән ишегалларын төзекләндереп тә бетергәннәр.

– Без койма кую яки шлагбаум урнаштыру белән шөгыльләнмибез. Ишегалдына яшеллек тә утыртмыйбыз, чөнки аны утыртып кына эш бетми, алга таба карап торырга да кирәк, – дип тә искәртте Арина Петрова.

Аның сүзләренә караганда, ишегалларында күбрәк зур чыгымнар таләп итә торган күләмле эшләр башкарыла. Мәсәлән, барлык чыгымнарның 80 проценты юлларга таш түшәүгә туры килә икән.

Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев әйтүенчә, республикадагы барлык программалар да яхшы, ә «Безнең ишегалды» – иң халыкчаны. «Һәркем көненә кимендә ике тапкыр – иртән һәм кич ишегалдыннан уза, ә төзекләндерелгән ишегалды кәефне күтәрә», – диде ул. Иҗтимагый киңлекләр дә мөһим, әлбәттә. Зөя утрау-шәһәрендә, мәсәлән, киләсе елда елга яр буен төзекләндерергә тәкъдим иткәннәр. «Биредә елына 1,7 миллион турист кунак була. Җирле халык туристлар шәхси йортлар арасыннан йөри дип зарлана. Төзекләндерелгән яр буе бу мәсьәләдә киеренкелекне бераз киметәчәк», – диде район башлыгы. Кайсы яктан карасаң да, тавыш бирү үзебезгә кирәк!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Тансык сәүдә

ЯРМИНКӘ БАШЛАНДЫ

Билгеле булганча, узган шимбәдә Казанда, Чаллыда, Яшел Үзән һәм Түбән Кама шәһәрләрендә язгы традицион ярминкәләр башланды. Алар 28 апрельгә кадәр һәр атнаның шимбәсендә узачак.

Шәһәр халкы әлеге ярминкәләрне көтеп ала, чөнки биредә авылдан килгән продукцияне арзанрак бәядән сатып алырга мөмкин. Билгеле, сыйфатлары да ышанычлы. Язгы сәүдәдә башлыча яшелчә, сөт, ит һәм балык күп сатыла.

– Безнең ярминкәләрне калдырганыбыз юк. Инде шушы еллар эчендә үзебезнең сатып алучыларыбыз да бар. Итләребезне көтеп торалар, шуңа күрә алып килгәнне тулысынча диярлек сатып бетереп кайтабыз. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы итне 480–500 сумга сатарга тәкъдим итә. Ләкин без әби-бабайларга, озак еллар бездән алучыларга арзанрак хакка – 440–450 сумга да җибәрәбез, – диде Кайбыч районыннан килгән фермер.

Апас районыннан Наилә Әхмәдиева исә ярминкәгә яшелчәләр алып килә. Бу юлы ул яшел суган саткан.

– Гадәттә без ярминкәгә бәрәңге, кәбестә һәм башка яшелчәләр сатарга көзен генә йөри идек. Бу юлы, сайлаулар булу сәбәпле, җирлек башлыклары бара алмады. Шуңа күрә безне җибәрделәр. Бик теләп бардым. Кыска гына вакыт эчендә шактый яшел суган сатылды. Сату булса, фермерга мондый ярминкәләр бик файдалы, әлбәттә. Көзен шуңа игътибар иттем: һәр яшелчәнең билгеле бер сатылу вакыты бар. Әйтик, сентябрь башында – бәрәңге, аннан соң – суган, соңрак кишер, чөгендер алалар, ә кәбестә сату иң ахырга – октябрь ахыры – ноябрь башына кала, – диде фермер.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ярминкәдә фермер үзе үстергән яшел суганның бер килограммын 150 сумнан саткан. Күпләп алучыларга да, аз-азлап алучыларга да шул ук бер бәя белән биргәннәр.

– Безнең мәйданчыкта суган сатучы башка кеше дә бар иде. Ул – алыпсатар. Килограммын 300 сумнан куйган, тик безнең бәяне күргәч, 250 сумга төшергән, дип әйтте сатып алучылар, – диде Наилә Әхмәдиева.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БӘЯЛӘР НИЧЕК?

Ит		**440** сумнан башлана
Йомырка	югары категориядәгесенең бер дистәсе	**130** сум
	беренче категориядәгесе	**108** сум
	икенче категориядәгесе	**103** сум
Сөт (1 литр)		**50** сум
Эремчек (1 кг)		**200** сумнан башлана
Дөге (3 кг)		**360** сум
Карабодай (3 кг)		**360** сум
Яшел суган (1 кг)		**150–300** сум

КИЛӘ ДӘ ҖИТӘ

БДИ – 2024

22 мартта БДИның алдан бирү этабы башланып, ул 22 апрельгә кадәр дәвам итәчәк. Узган ел Татарстанда 109 кеше язылган булса, быел андыйлар – 27. Чыгарылыш укучылары сынауларга ничек әзерләнә?

БДИны алдан тапшыру хокукы сәламәтлек яки халыкара чараларда катнашу сәбәпле, төп этапта катнаша алмаучыларга бирелә.

– Аларның күбесе – мәктәпне узган елларда, шулай ук урта һөнәри уку йортларын тәмамлаучылар, – диделәр Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәгендә.

Мәктәпләргә шалтыратып, БДИны алдан бирүчеләрне эзләгән идек, әмма таба алмадык. Андыйлар сәләтле балалар белем ала торган лицейларда да юк.

– Бездә һәрвакыт сынауларны үз вакытында тапшыралар. Быел БДИны 98 кеше бирәчәк, – ди КФУның Лобачевский исемендәге лицее директоры Елена Скобельцина. – Сынауларга әзерләнүнең системасын булдырдык. Дәресләрдә дә өйрәнәләр, өстәмә чаралар да бар. Әйтик, укучылар үзара төркем оештырып, бер-берсенә булыша. «Кешене өйрәткәндә, үзең дә өйрәнәсең». Безнең шигарь шундый. Берәү бер теманы сөйли, икенчесе башканы. Кемдер белгеч буларак хаталарын төзәтә. Шулай итеп, иң катлаулы сорауларга да җавап табыла. Бу – хәтердә калдыру өчен иң яхшы ысул.

Елена Скобельцина әйтүенчә, лицейда репетитор сүзен әйтү тыела. Мәктәпләрнең вазыйфасы – белем бирү. Бу – иң идеаль картина. Ә менә аларның репетиторлары бармы, юкмы икәнлеген директор әйтә алмады.

11 нче сыйныф укучылары бармак бөгеп, көннәрне саный. Тиздән сыналыр чак җитә.

– БДИ хакына миңа хәтта уку йортын үзгәртергә туры килде. 11 нче сыйныфка башка мәктәпкә күчтем. Анда БДИга яхшы әзерлиләр, диделәр. Бары «5ле»гә генә укыйм. Хыялым – туризм яки чит телләр юнәлеше буенча китү, – ди Балтач урта мәктәбе укучысы Гөлсем Зыятдинова.

Алмаз Шәйхетдиновның теләге – программист булу. Исәбе Казан дәүләт энергетика яки Казан илкүләм тикшеренүләр техник университетына укырга керү.

– Ел башыннан борчылган иде, инде тынычланды кебек. Репетиторлар ялламадык. Математика һәм информатикадан курслар сатып алдык. Айга 8әр мең сум китә. Акча җәл түгел, имтиханнарын гына яхшы тапшырсын, – ди дүрт бала әнисе Фидәлия Шәйхетдинова.

Сәрия МИФТАХОВА

Киңәш

Рәис МӨХӘММӘТҖАНОВ, Казан дәүләт медицина университеты студенты, химиядән 100 балл туплаган Саба егете:

✓ Белем булса, курку булмый. Үзегезне тыныч тотыгыз. Бу – иң мөһиме.

✓ БДИдан 100 балл туплаучы бар нәрсәне дә белә дип уйлыйлар. Әмма бу алай ук түгел.

✓ Сынауны яхшы бирү өчен көн саен вакытны бүләргә кирәк. Җәй көне көнгә 2–3 сәгать шөгыльләндем.

✓ Төнлә йоклагыз. Йокы организмга ял бирә.

shayantv.ru

БАЛАЧАК ҖЫРЫ

Газетабызда узган ел ахырында балалар репертуарына бәйле язма чыккан иде («Җырланмаган җыр», 22 декабрь, 2023 ел). Әлеге язмадан соң кайтавазлар күп булды. «ШАЯН ТВ» балалар телеканалына рәхмәт: өстәл янына җыеп, кабат фикерләшү мөмкинлеге тудырдылар.

Очрашуда катнашучылар: *Әлфия Җәббарова (Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор, «Балачак җыры» бәйгесенең жюри әгъзасы), Сәгыйть Хәбибуллин (Казан консерваториясе профессоры, «Балачак җыры» бәйгесенең жюри рәисе), Гөлназ Гафурова (җырчы, укытучы), Роза Әдиятуллина («ШАЯН ТВ» каналы башкарма директоры беренче урынбасары).*

:: «Балалар репертуары нишләп сай икән?» дигән сораудан башлыйсы килә.

Сәгыйть ХӘБИБУЛЛИН:
– Сез күтәргән сорау бик актуаль ул. Дөрес әйтәсез, бала ни ишетә, шуны җырлый. Кемнән тора соң бу? Иң элек – укытучыларыннан. Балага җырны алар бирә бит. Җыр дәресләрен алып барган кеше үзе бу дөньяны күзәтеп барырга тиеш. Зур сәхнәгә балалар ата-ана өйрәткән җыр белән чыкмый, аларның музыка укытучылары була. Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән «ШАЯН ТВ» каналы оештыра торган «Балачак җыры» телевизион проектына бик күп җырлар килә. Иләк аша үткәреп, шулар арасыннан сайлап, менә дигән җыр җыентыклары чыгаралар. Матур җырлар бар, тик аларны пропагандалау җитми. Авторлык хокукы дигән кыса да бар. «Балачак җыры» бәйгесенең өстенлеге – җиңгән җырларны теләсә кем җырлый ала. Башка бәйгеләрдә исә җырларга «безнеке» дип ябышып торалар. «ШАЯН ТВ» бу яктан бик тә юмарт.

Роза ӘДИЯТУЛЛИНА:
– «Балачак җыры»ның максаты да – шул җырларны тарату. Профессиональ жюри йөзләгән җырдан башта 20 җырны сайлый. Аннары безнең каналның сайтында тамашачылар тавыш бирә. Жюри, тамашачылар фикерен исәпкә алып, биш җырны сайлап ала. Без жюрига авторларны әйтмибез, алар җырны тыңлап бәяли. Биш җырның авторларын бары тик бүләкләүдә генә күрәләр. Ел саен «Балачак җыры»нда җиңүчеләрне комиссия рәисе Марат Әхмәтов үзе килеп тәбрикли. Җиңүчеләр 50шәр мең сум премия алалар. Җиңгән җырларга сыйфатлы аранжировка ясыйбыз, клип төшерәбез. Биш ел эчендә 20 җыр туды! Әзер минусовка, җыр текстлары, ноталары, видеоклип канал сайтында урнаштырыла. Теләгән һәркем үзенә алырга мөмкин. Без нота китапларын, җыентыкларны Татарстан буенча тараттык. Шуннан соң зур бәйгеләрдә, төрле чараларда безнең проектның җырлары яңгырый башлады. Димәк, бу җырлар үз башкаручысын таба! Сүз уңаеннан, Казан мәктәпләрендә һәм мәдәният сарайларында «Балачак җыры»ның 36 концертын күрсәттек, аны 15 меңгә якын бала карады.

Гөлназ ГАФУРОВА:
– Безнең Казан филармониясендә балалар ансамбле бар. Аларга махсус җырлар яздырабыз. Конкурсларда, концертларда чыгыш ясаганнан соң, бездән: «Бу җырны алсак ярыймы?» – дип сорыйлар. Мин бишкуллап ризалык бирәм. «ШАЯН ТВ» зур эш башкара. Безгә – педагогларга да, ата-аналарга да эшне җиңеләйтәләр.

Сезнең дә балалар репертуарын яңа татарча җырлар белән баетырга теләгегез бармы? «Балачак җыры» бәйгесенең бишенче юбилей сезоны башланып китте. Бәйгедә катнашу бушлай. Җырның текстын һәм көен «ШАЯН ТВ»га юлларга мөмкин. Гаризалар 30 апрельгә кадәр **shayanmuzik@mail.ru** аша кабул ителә. Бу бәйгегә үз эшләрен теләге булган һәркем җибәрә ала.

Татар җырларын яклап та сүз әйтергә телим. Әйтик, рус эстрадасындагы текстларны карасаң, анда ни генә юк! Бездә җырлар мәгънәле. Мисалга, «Балачак җыры»нда җиңгән «Дуслар күп булсын» җырын яратып башкарабыз. Клипта да төштек. Кайда гына чыгыш ясасак та, бу җырны кат-кат сорыйлар. Без «Балачак җыры» дип аталган концертлар циклында да актив катнашабыз.

Сәгыйть ХӘБИБУЛЛИН:
– «Балачак җыры» дигән җыентыкны кулга алуга аның матур итеп эшләнгән булуына сөенәм. Музыка дәресләрендә кулланыла торган уңайлы китап. Бер тәкъдим туды әле. Укытучыларның август киңәшмәләре була бит әле. Бәлки, музыка укытучыларын бер урынга туплап, аларга семинар рәвешендә очрашу оештырыргадыр? Алар бит, чынлап та, күбесе бу җырлар турында белми. Укытучыда да эзләнү булырга тиеш.

Әлфия ҖӘББАРОВА:
– Җыр сайлаганда тандем булырга тиеш: әти-әни – бала – укытучы – уку йорты. Баланың тавышы нинди җырга ята, психологиясенә нәрсә туры килә – укытучы моны яхшырак белә.

:: Зәвыклы җыр җырлата алырдай укытучыларны да тәрбияләргә кирәк, димәк?

Әлфия ҖӘББАРОВА:
– Балаларга беренче сыйныфтан ук җырны хөрмәт итү хисен сеңдерү, музыканы анализларга өйрәтү мөһим. Акыллы тыңлаучы үстерергә кирәк. «Балачак җыры» бәйгесе – моңа ачык мисал.

Сәгыйть ХӘБИБУЛЛИН:
– Бала «попса» белән тәрбияләнә. Телевидениедә дә күбрәк шул инде. Алар халык җырлары, композитор җырлары һәм башкалары кирәкми дип үсә. Бу бездә генә шулай түгел, ил буенча шулай.

Әлфия ҖӘББАРОВА:
– Бәлки, белем бирү йортларына мәдәният һәм сәнгать белгечләреннән «десант»лар оештыру да кирәктер? Җыентыклар, китаплар алып килсеннәр. Җыентыклар дигәннән, аларны да яңартып чыгару кирәк инде. 10 елдан соң безгә моның өчен оят булмасын. «Нишләп безгә боларны калдырмадыгыз?» димәсеннәр.

:: Цифрлы китапханә, цифрлы архив та кирәк. Музыка да, җыр да – сакларга кирәк булган мирас.

Әлфия ҖӘББАРОВА:
– Аннан, музыка буенча белем бирүче белгечләрне җыеп, форум үткәрергә дә буладыр. Аларның проблемаларын ишетергә кирәк. Сүз дә юк, «нагрузка» дип, кайберләре музыка белән бергә башка фәнне дә укыта. Әмма бит музыка – математика кебек үк фән. Хаталансаң – бетте.

Күбрәк аралашу кирәк, димәк. Әмма һич кенә дә тәнкыйтьләмәскә. Гасырлар дәвамында башкарылган эшне «юк» дип, күрмичә калырга ярамый.

Шәхесләрне дә күтәрергә, күрсәтергә кирәк. Хәзер яшь композиторларның күбесе әнә мәктәпләрдә белем бирә. Искиткеч бит!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Иман

Бала күңеленә ак юл

«Рауза» мәчете эшли башлаганга елдан артык кына вакыт узды. Мең шөкер, Аллаһ йортының ишеген өлкәннәр генә түгел, балаларның да ачып керүе безнең өчен зур шатлык. Яшьләр, балалар булган урынның киләчәге дә өметле була.

Мәчетебездә икенче ел укулар алып барыла. Гаилә кыйммәтләрен, милли рухны алга сөрүче мәчетебез балалар, яшьләр арасында төрле чаралар уздыра. Дин гыйлемен алган остазлар аларга татар гаиләсенең нинди булырга тиешлеген дә аңлаталар, дини белемнәрен арттыруда да үзләренең киңәшләрен бирәләр.

Мәчетебездә татар мәкаме белән азан әйтү буенча остаханә узуы – моның ачык мисалы. «Рухи моң» иҗат берләшмәсе остазлары – Марсель Әхмәдуллин белән Марсель Вәгыйзов мәчеткә йөрүче шәкертләргә азан әйтүнең нечкәлекләрен төшендерде. Азан әйтүнең дә үз таләпләре бар. Аны бер дәрестә генә үзләштереп бетереп булмый. Моны истә тотып, киләсе уку елында остазлар мәчеткә йөрүче ир балаларга азан әйтергә өйрәтәчәкләрен дә җиткерделәр. Беренче дәресләр алган ир балаларның осталыкларын тикшерү максатыннан мәчетебездә азан әйтү буенча ярышлар узды. Әлеге бәйгегә Совет районында яшәүче 21 бала килгән иде. Егетләр үз көчләрен сынап кына калмыйча, күренекле җырчыбыз Миңгол ага Галиевтан алтынга тиң киңәшләр дә ишетте. Аңа кадәр, декабрь аенда дини гыйлем үзләштерүче малайлар арасында Коръән уку буенча бәйге узган иде. Анда 31 бала катнашып, ике номинациядә – Коръәннең соңгы 10 сүрәсен һәм 30 нчы җүзне яттан укуда көч сынаштылар. Шушындый ук бәйге күптән түгел кызлар арасында узды. Коръән уку бәйгесенә Совет районында эшләп килүче 11 мәчеттән 40 кыз катнашты. Россия һәм Татарстан мөслимәләре берлеге рәисе Наилә Җиһаншина матур итеп киенеп килгән кызларга җылы сүзләрен җиткереп, аларга ак юллар теләде, тагын да тырышып Коръән аятьләрен ятларлык көч өстәп, аларны рухландырды.

Мәчетебездә балалар арасында уза торган бу чараларның барысында да «Рауза» мәчетен төзетүгә бик күп көч куйган Радик Гайзатуллин шәхсән үзе катнашып, яшь буынга ихлас теләкләрен җиткереп, әнисе Рауза абыстай исеменнән истәлек бүләкләре тапшыра. Радик Рәүф улы һәр очрашуда балалар күңеленә иман ачкычы таба белә, аларны үсендерерлек сүзләр җиткерә. Бала күңелендә мәңге калырлык мизгелләр бүләк итә. Аларга ак юл, бәхетле киләчәк теләп, Аллаһ юлыннан тормыш сукмагын дәвам иттерергә киңәш итә.

Билгеле, моңа кадәр республикабызның күренекле кешеләрен телевизордан гына күргән бала, мәчетебезгә килгәч, югары дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр белән очраша, алар биргән хәер-догалар ярдәмендә конкурсларда җиңү яулый. Һәм бу матур мизгелләр аның күңеленә мәңге онытылмаслык булып уелып кала. Иманыбыз камил, ул үсеп җиткәч, бу хакта үз балаларына да җиткерер, әти-әнисе аны җитәкләп мәчеткә алып килгән кебек, ул да баласын шушы изге юлдан йөртергә тырышыр.

«Рауза» мәчете ишекләре һәр мөселман өчен ачык. Без инде киләсе уку елы турында да уйлана башладык. Октябрь аенда кабаттан укулар башланачак, сезне «Рауза» мәчете мәдрәсәсендә көтеп калабыз.

Илнур хәзрәт ВАФИН, «Рауза» мәчете имамы

ХӘЙРАН КАЛЫРЛЫК БУЛДЫ

Мәктәпләрдә

Казан шәһәренең 171 нче мәктәбенә кунакка чакырдылар. Зур гына бер чара. Темасын хәтта катлаулы дип тә әйтергә мөмкин. Гадәттәгечә балалар залга кереп тулды. Контрольдә тотар өчен диптер инде, укытучылар да рәт араларына сибелде. Мәктәпләрдә күп булырга туры килә бит инде. Эчтән генә уйлап утырам: «Тыңламаслар инде, түземлекләре җитмәс, сөйләшеп утырырлар».

Әмма хәйран калдым. Кая ул сөйләшү, сораулар бирә-бирә, белергә, ачыкларга теләп, кунакларның җелегенә үттеләр. Иң гаҗәпләндергәне шул: чараның яртысы диярлек татар телендә узды. Аңлыйлар, димәк.

Хәл итү юлы

Мәктәп директоры Рания Галиәкбәровага да беренче соравым шул хакта булды, чөнки ул үзе дә татар телендә чыгыш ясады.

– Аңлыйлар. Әгәр алай булмаса, сораулар биреп, кызыксынып утыра алмаслар иде, – диде директор, елмаеп. Канәгатьлеге йөзенә чыккан үзенең.

Ә моңа ничек ирешергә? Монысы икенче саллы сорау иде.

Эшләнгән эшләр күп булып чыкты.

– Белем бирү белән тәрбия системасын аерып карамыйбыз без, – дип башлады сүзен Рания ханым. – Дөресен әйтик, хәзер ата-аналарның балалар белән аралашырга әллә ни вакыты юк. Шуңа күрә балалар телевизор каршында, төрле гаджетлар алдында «дөнья көтәләр». Бу исә сөйләм теленең үсешен тоткарлый. Сөйләм теле дигәндә рус, татар, башка телләр дә күздә тотыла. Башта шушы проблеманы ничек хәл итәргә дип уйландык. Әлбәттә инде, җавабы гади: балалар күңеленә якын булган эш формаларын сайларга кирәк. Без берьюлы ике куянның койрыгын тотарга булдык: чараларны нигездә татар телендә үткәреп, шуның белән сөйләм телен дә үстерергә һәм телне дә ныгытып өйрәнергә. Барып чыкты дип әйтергә була. Уңышларыбыз да шактый.

Театр яктылыкка, нурга илтә

– Театр турындагы шушы сүзләр юкка гына канатлы гыйбарәгә әйләнмәгәндер, дидек тә эшне зурдан кубып башладык. Татарстанның атказанган артисты Фердинанд Хафизов белән театр түгәрәге эшчәнлеген башлап җибәрдек. Башта теләүчеләр берән-сәрән генә иде, читтән генә күзәтеп йөрделәр. Төрле бәйгеләрдә катнашып, нәтиҗәле урыннар ала башлагач, кызыксынучылар икеләтә артты, татарлар гына түгел, башка милләт балалары да теләк белдерде.

Нәтиҗәләр искиткеч булды. Туфан Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» пьесасын сәхнәләштереп, шәһәр буенча беренче урын, Россиякүләм балалар һәм яшьләр театр коллективлары арасында Зәки Зәйнуллинның «41нең арбалы хатыннары» белән икенче урын, «Әлмәндәр варислары» фестивалендә өченче дәрәҗә дипломга лаек булдык. Болар – җиңүләребезнең бер өлеше генә.

Максатыбызга ирештек. Балалар, телефоннан күзләрен алып, иҗат дөньясында кайный башладылар. Бер генә бәйгене дә күз уңыннан ычкындырмыйлар. Район, шәһәр, республика күләмендә уздырылган «Татар кызы», «Татар егете», «Көз сылуы Сөмбелә», «Мин бит – татар малае» бәйгеләренең барысында да диярлек безнекеләр призлы урыннар яулый.

Ватанпәрвәрлек

– Бүгенге баланы театр, җыр-бию белән генә кызыктырып булмый, әлбәттә. Бик үк дөрес тә булмас иде. Әмма, әйткәнемчә, сөйләм телен үстерү ул башка өлкәләргә дә юл ача. Бездә дә шулай булды. Португалиянең Лиссабон шәһәрендәге беренче славян мәктәбе белән элемтәләр урнаштырдык. Төркиянең Анталия шәһәрендә урнашкан Мәскәү мәктәбе белән дә җылы мөнәсәбәтләр булдырылды. Укучылар ике яктан да җирле гореф-гадәтләр турында белемнәре белән уртаклашалар, биеп, җырлап күрсәтәләр. Чит илләр, башка милләтләр белән аралашу ватанпәрвәрлек хисләре тудыра, тарихны өйрәнүгә этәрә. Бу җәһәттән музей эшләре дә ярдәмгә килә, дип уйлыйм. Бездә 2003 елдан беренче татар математика профессоры Хәмит Мөштәри музее эшли, 2019 елда танылган татар җырчысы Рәшит Ваһапов музее ачылды. Укучылар шунда белемнәрен ныгытып, татар, рус, инглиз телләрендә микрорайонда яшәүчеләр, кунаклар өчен экскурсияләр үткәрәләр.

Замана үзгәреп тора

– Бөек татар галиме Риза Фәхретдиннең мондый сүзләре бар: «Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр». Бик дөрес. Без кайчагында, чыннан да, үз каланчабыздан гына карый башлыйбыз. Шуңа күрә балалар кызыксынырлык берәр заманча чарага юлыксак, без аны шундук тотып калырга тырышабыз. Мәсәлән, галәм серләрен өйрәтүче «Җиһангирлар» марафоны шундыйлардан. Бу чара кысасында без Россия Герое, летчик-космонавт, Бөгелмәдә туган якташыбыз Сергей Рыжиков, Америка корабында галәмгә күтәрелергә җыенган Фәрит Әюпов белән дә очрашырга өлгердек.

Әмма «Белем Әлифбадан башлана» дигән гыйбарәне дә онытмыйбыз. Әллә кайларга «очып» киткәнче, бала янәшәдәге, гаиләдәге, мәктәптәге хәлләргә бәя бирә белергә, аларны кадерләргә тиеш. Бу җәһәттән Арча шәһәрендәге Туган як, Әлифба музейларын карап кайткач, хисләренә чик-чама булмады. Укучыларыбызның татар теле буенча республика, халыкара олимпиадаларда җиңү яулавы – менә шушы эшләрнең нәтиҗәсе дип беләм.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

Извещение о необходимости согласования проекта межевания
Кадастровым инженером Гайнуллиным Ранилем Рифатовичем (СНИЛС № 056-589-745 20, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность № 13024, 420059, г. Казань, Оренбургский тракт, д. 8А, ranil.rg@yandex.ru, тел.: 8-9050386407) подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером: 16:33:170416:144, расположенных по адресу: Республика Татарстан, Пестречинский муниципальный район, Шалинское сельское поселение.
Заказчиком кадастровых работ является Гимадиев Радиф Ильдарович. Тел.: 89969034686.
С проектом межевания земельных участков можно ознакомиться по адресу: 420059, г. Казань, Оренбургский тракт, д. 8А, ком.108 с 8.00 до17.00 ч.
Обоснованные возражения по проекту межевания и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с даты выхода газеты в течение 30 дней по адресу: 420059, г. Казань, Оренбургский тракт, д. 8А, ком. 108. Тел.: 8 (843) 570-19-02, факс: 8 (843) 277-57-37 и дополнительно по адресу заказчика: РТ, Пестречинский район, д. Шали, ул. Тукая, д. 156.

Хисле дөнья

Сары ул – бәхет төсе!

Сез бүген Халыкара бәхет көне икәнен беләсезме? Әллә белми йөрисезме? Акыллы кеше бәхетне көтеп ятмый, дигән безнең халык. Һәркемнең бәхете – үз кулында, дигән гыйбарәне дә ишеткәнегез бардыр. Шулай булгач, бүген – бәйрәм көнне генә булса да, үзебезне бәхетле итик әле!

Ни кызганыч, иң бәхетле илләр исемлегендә Россия нибары 70 нче урында гына. БМО 2023 елда тәкъдим иткән рейтингның беренче урынында – инде алтынчы ел рәттән Финляндия. Дөрес, сөенергә дә җирлек бар: Россия бер ел эчендә 10 баскыч өскәрәк күтәрелгән.

Ә кешене нәрсә бәхетле итә? Билгеле, һәркемнең – үз җавабы. «Тәртип» радиосы баш мөхәррире **Ризәлә Исмәгыйлева** менә болай дип җавап бирде:

– Бәхет ул – беренче чиратта, сәламәтлек. Кеше кайчан сәламәт була? Шөкер итә, канәгать була белсә, юк-бар белән үзен «йолкымаса», матурлыкны күрә белсә. Без кайвакыт ап-ак кәгазь битенә төшкән бер кара тамчыга игътибар итәбез, ә кәгазьнең ак өлешен бөтенләй күрмибез. Тормышта, ни кызганыч, гел шулай. Менә шул ак өлешен күрергә өйрәнсәң, бәхетле буласың инде, – диде ул безгә. – Кешеләргә чын күңелдән яхшылык эшли алу да – бәхет. Көнләшмичә яшәү, башкаларга теләк тели алу да – бәхет. Гомумән, «бәхет» төшенчәсе үз эченә шундый күпне ала!

Әлеге фикерне практик психолог **Зөһрә Кәримова** да дәвам итте.

– Игътибарны нәрсәгә юнәлдерәсең – шунда бәхет табып була! Гел начарны гына күреп, шул турыда гына уйлыйсың икән, үзеңә шуны тартып китерәчәксең. Шуңа да көн саен сине бәхетле итәрдәй сәбәпләр эзләргә һәм табарга кирәк. Кайчак күңел торышы вак кына нәрсәләргә бәйле була. Бәхетле булырга ничек өйрәнергәме? Һәр көннең, һәр сәгатьнең кабатланмас һәм үзенчәлекле булуын аңларга гына кирәк, – дип уртаклашты ул.

Яман шешне җиңгән 43 яшьлек **Гөлнара Гәрәева** өчен дә бәхет – беренче карашка гап-гади тоелган нәрсәләр.

– Үзеңнең һәм якыннарыңның сәламәтлеге – иң зур байлык һәм бәхет ул. Өченче атна инде улым авырый, үземә урын таба алмыйм. Һәм һәрвакыт шулай бит. Кызганыч, без күреп кенә бетермибез. Әмма гап-гади нәрсәләр дә кешене бәхетле итә бит. Аяк-кулларың сау булса, күзләрең күрсә, колакларың ишетсә, яраткан эшең, якыннарың белән очрашырга вакытың булса, бәхет өчен тагын нәрсә кирәк?!

Килешәсездер, бәхет – хатын-кызлар темасы, дигән фикер яши. Чыннан да, бу төшенчә турында хатын-кызлар күбрәк уйлана бит. Гади генә мисал: социаль челтәрләрдә бу хакта гәп куертучылар, аның серен аңлатырга тырышып, хәтта акча эшләүчеләр дә – хатын-кызлар. Шулай да, ир-атлар бу хакта ни уйлый?

– Мине тынычлык һәм тормыштан канәгать булу бәхетле итә, – дип, кыска гына җавап бирде Татарстанның халык артисты **Вадим Захаров**.

Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев** әлеге сорауга менә ничек җавап биргән булган:

> Бәхет, оҗмах шикелле, һәрвакыт алда. Ул шундый хыялый, серле бер көчтер инде. Бәхет ул матди хәл дә була алмый, аны тотып карап булмый. Күңел түрендәге хис, рух, шатлык, канәгатьләнү халәте ул. Сау булыйк! Бәхетле булыйк!

pinterest.com

Бәхет турында бәхетле фактлар

Без сары төсне сагышка юрарга күнеккән. Ә ул – бәхет төсе. Берәр көн сары киемнән йөреп карагыз әле. Икенче көнне сорыдан киенегез. Кәефегез ничек үзгәрер икән?

Миннесота университеты галимнәре ачыклавынча, бәхетнең 50 проценты – геннарга, 40 проценты – уйларыбызга һәм 10 проценты әйләнә-тирәбезгә бәйле.

Башкаларга акча тоткан вакытта без үзебезне бәхетлерәк хис итәбез икән! Моны раслау өчен махсус эксперимент уздырганнар. Ике төркем кешегә бертигез акча биргәннәр. Бер төркем бу акчаны – үзенә, икенчесе башкаларга тоткан. Нәтиҗәдә икенче төркемгә кергән кешеләр үзләрен бәхетлерәк хис иткән!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КОШЛАРГА ДА ӨЙ КИРӘК

Оста куллар

Манаралы һәм айлы, капка-коймалы, бизәкле һәм гап-гади. Биектау районының Олы Битаман авылында яшәүче Гомәр Гарифуллин кошларның җылы яктан кайтуларын әнә шулай матур оялар ясап, зур әзерлек белән каршы ала.

– Мин яшь вакытта комбайн йөрттем, кышларын кулга балта тотып, тәрәзә кысалары, капка, ишекләр, шкаф, өстәл, урындыклар, кыскасы, агачтан нәрсә эшләп була – барысын да эшли идем. Йорттагы һәр җиһазга минем кул хезмәтем салынган. Үземнең кулдан килгәч, кемгә кушасың инде тагын?! Өйдә тик кенә ятып булмый бит, кәеф булмаса да, эч пошып торса да, шушы остаханәмә чыгам, – дип елмайды ул.

Пенсиягә чыккач та балтасын читкә куеп торырга ирек бирмиләр үзенә. Заказлар килеп кенә тора, тик хәзер инде бик сайланып кына кабул итә аларны. Башлыча тәрәзә өлгеләре, кечкенә урындыклар, эскәмияләр, мунча сәкеләре ясый. Алар арасында иң яратып һәм, үзе әйтмешли, «ял иткән арада» башкара торганнары – кош оялары.

– Менә бу сыерчык оясын өч көн эшләдем, – диде Гомәр абый, буралап эшләнгән бик матур ояга төртеп күрсәтеп. – Интернеттан фотосын күргәннәр дә, нәкъ шундый укны эшләп бирүемне сорадылар. Ләкин мондый ояны бик сирәк, заказга гына эшлим. Гадәтиләрен күбрәк сатып алалар. Аларын көнгә өч-дүртне ясыйм. Ләкин бервакытта да ашыгып, кабаланып эшләмим. Үз җаема гына башкарам. Болардан тыш, манаралы ояларны да яратып алалар. Балалар Биектауда яши, заказларны күбрәк шулар алып кайта. Эшсез торганым юк, гел сорап кына торалар. Кышын буш вакытта эшләп куям да, язын сатып алып бетерәләр.

Бәяләренә килгәндә, алар катлаулыкларына карап, төрлечә. 600 сумнан башланып, 2500 сумга кадәргеләре бар.

– Кышын җимлекләрне күп алалар. Язын ояларны алып бетерәләр. Сыерчыклар кайтты бугай инде. Шуңа күрә сезон башланды, дип әйтергә була. Сорашучылар, кызыксынучылар артты. Кошлар, җылы яклардан кайткач, башта урманга китәләр. Унбиш көнләп узгач, кире авылга төшәләр. Менә шул вакытта инде аларга оя кирәк. Оя алу сезоны якынча өч атна тирәсенә сузыла, шул вакытта гадәттә иллеләп кош оясы сатыла, – ди ул.

Оста әйтүенчә, сыерчык оясы өчен нарат агачы яхшы.

– Мин ояларны буямыйм, чөнки кошлар буяу исен яратмый, диләр. Алай дисәң, буялганнарына килгәннәрен дә күргәнем бар инде. Буямаган оя тиз чери, шунысы начар, – ди Гомәр Гарифуллин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Кошларга бәйле сынамышлар

- ✓ Карга килсә, кыш китәр.
- ✓ Аккош иртә килсә, яз начар булыр, озак торыр.
- ✓ Акчарлак килгәч, елгаларда боз тиз кузгалыр.
- ✓ Ала карга агач башына кунса, яз тиз, җиңел килер, җиргә кунса, озак килер.
- ✓ Апрельдә торна кычкырса, ел яхшы килер.
- ✓ Торна биесә, һава җылыныр.
- ✓ Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
- ✓ Әгәр торналар берәм-берәм килсәләр, җәй яхшы булыр.

Белгеч фикере

Илгизәр РӘХИМОВ, орнитолог:

– Әлеге вакытта җылы яклардан акчарлак, кара карга, кызылтүш, соры чыпчыгы һәм башка вак кошлар кайтты. Казанда күренмәсәләр дә, сыерчыклар да Татарстанга кайтты, авылларда күрүчеләр бар.

Халык сыерчык ояларын элек-электән ясады. Кызганыч, хәзер андый традиция югалып бара. Кайбер мәктәпләрдә сыерчык ояларын ясау бәйгеләре уздыралар. Ләкин анда ясалган ояларның күпчелеге шартларга туры килми. Аларның күпчелегенә сыерчык ояламый. Аны ясар өчен кулланылган тактаны шомартырга кирәкми. Ояның эче ышкы белән ышкылмаган, ягъни кытыршы булырга тиеш. Бу кошларга тырнаклары белән ябышып менәргә уңайлы булсын өчен кирәк. Артык бизәкле, чуар оялар да кошлар өчен уңайсыз. Кош «йорт»ларын буярга да кирәкми: кошлар буяу исен өнәми. Шулай ук алдагы елларда куелган кош ояларын чистартып, чүпләреннән арындырып торырга кирәк, чөнки анда яткан әйберләр бозылып, ояның идәнен черетә. Андый ояга кошлар килми инде. Гадәттә бер оя аларга өч ел хезмәт итә. Кош керә торган «ишек»не дә әллә нинди формаларга китереп ясарга кирәкми. Иң яхшысы – гап-гади түгәрәк тишек. Карга, башка ерткыч кошлар кереп, сыерчык балаларына зыян китермәсен өчен, аның диаметры 4–5 сантиметрдан артмаска тиеш.

Моннан тыш, оя ясауның үз кагыйдәләре булган шикелле, аны урнаштыру тәртибе дә бар. Беренчедән, оя көньяк яки көнчыгышка таба карап торырга тиеш. Икенчедән, ояны булдыра алганча биегрәк элү кирәк. Өченчедән, бер агачка берничә оя эләргә ярамый. Аларның аралары якынча ун метр чамасы булырга тиеш. Менә шушы кагыйдәләр үтәлеп бетмәгәнгә сыерчыкларны Казаннан куып бетердек инде. Хәзер аларны авылларда, урман, дача тирәләрендә генә очратырга мөмкин.

АКЛЫК ЭЗЛӘП ҮТКӘН ГОМЕР

Соклану

«Әниебез «Ватаным Татарстан»ны яратып укый!» Чаллыда яшәүче Роза Вәлиева әнә шулай дип сүз башлады. Аларга газетабыз атнага өч тапкыр килә. 95 яшьлек әниләре газетаның бер хәрефен дә калдырмыйча укып бара.

– Әниебез Актаныш районының Табанлы Күл авылында туа. 9 яшендә үк эшли башлый. Башта басуда башак чүплиләр. Бераздан көлтә бәйләтә башлыйлар. Ул вакытта уракны ат белән урганнар. Әни алдан юл да салып барган әле. Имгәнгән дә, киселгән дә, – дип сөйли әнисе хакында Роза апа. – Бик авыр яшәгәннәр. Шуңа карамастан, әни укуын ташламый. Мәктәпне тәмамлагач, аны балалар йортына тәрбияче итеп куялар. Сугыштан соң ятим калган балаларны юату җиңел булмый. Яшь-яшь булса да, әнием бу сабыйларга үз җылысын бирергә тырыша. Күңелендә мәрхәмәтлек медицина өлкәсенә китерә дә инде аны. Әмма аңа кадәр урау юллар уза әле ул.

Ракига апа 1951 елда укырга керәм дигәндә генә, әтисе авырып китә. Кызны декрет ялына киткән укытучы өчен эшкә куялар. Шулай итеп, 4 ел узып та китә. Күңелдәге теләк барыбер үзенекен эшли: 1955 елда Ракига апа Минзәлә медицина училищесына укырга керә. 3 елдан кулына диплом алып, Югары Яхшый авылына эшкә кайта. Ул вакытта авылда медпункт та юк, ә авырулар күп. Яшь кыз куркып калмый, өйдән-өйгә йөреп, кешеләрне дәвалый. Аннары иске генә өйне төзекләндереп, медпункт ясыйлар.

«ВТ» уйнаткан бәйгедә дә бик теләп катнашты Ракига апа.

– Ул бик салкын иде. Кыш көне хәтта дарулар ката иде. Ә бер язда эшкә килеп ишеген ачуым булды, түбәсе ишелде дә төште. Әле ярый эчтә кеше юк иде, – дип искә ала Ракига апа. – Шуннан соң китапханәне медпункт иттеләр. Ә 1975 елда авылда яңа медпункт төзелде.

Ул елларда авылларда тормышның кайнап торган чагы. Халык күп, авыручылар да җитәрлек. Ракига апа эшен җиренә җиткереп башкара. Кайдадыр таләпчәнрәк тә булырга туры килә, кайчак чисталык өчен дә көрәшә. Дәва эзләп, медпункт ишеген ачкан егет гомерлек яры да булып куя.

Тәлгать абыйның күзенә чүп кергән була. Яшь фельдшерны ул бер күрүдә ошата. Алар 1958 елда гаилә коралар. Уллары Фазыл белән кызлары Роза туа.

– Әнинең теләсә кайчан өйдән чыгып китүенә кечкенәдәнияләштек. Без аның хезмәтенең никадәр җаваплы булуын аңлап үстек. Шөкер, әниебезнең эшләгәне дәүләт җитәкчеләре тарафыннан да бәяләнде. Аллаһы Тәгалә озын гомер белән бүләкләде. Әйтерсең, кайчандыр ярдәм кулы сузган, авыруына дәва тапкан кешеләрнең рәхмәтләре әнә шулай килеп ирешкән, – ди Роза апа. – Кызганыч, абыем Фазыл моннан өч ел элек вафат булды. Әтиебез үлгәч, абыем әни янына күченеп кайткан иде. Гаиләсе Ижауда калса да, йә абый барып йөрде, йә киленебез кайтып торды. Әнием бала хәсрәтен дә сабыр күтәрде. Инде хәзер әни белән бер-беребезгә юаныч булып яшибез.

Ракига апа да заманында күзләре сукырайган әнисен баладай тәрбияләгән. Әнә шул матур үрнәк аның үз балалары күңеленә дә сеңгән инде. Игелек эшләүнең, ата-ана ризалыгының ни икәнен белә алар. Хәер-догасыз да яшәп булмый бит әле.

– Әнием – йөгерек зиһенле, бик сабыр, пөхтә, дөреслек ярата торган кеше. Безне эшкә өйрәтеп үстерде. Еш кына ничек бөтен эшкә өлгерде икән дип уйланам. Йортыбыз чиста, тәрәзә төбендә гөлләр шаулап чәчәк атып утырды. Камыр ризыклары да пешерер иде. Умарта да тотты. Мин аның, урамга чыгып, капка төбендә ял итеп утырганын хәтерләмим. Ул гел эштә иде, – ди Роза апа. – Мин үзем дә олы яшьтә инде. Әмма әле дә әнием җылысын тоюым белән бәхетлемен. Әниле кеше – бәхетле кеше ул. Кайтып кереп, «әни» дип эндәшер кешем бар. Әниемнең балачагы бик авыр булса да, картлыгы матур. Ә без – балалары, оныклары, оныкчыклары аны тагын да бәхетле итәр өчен барысын да эшләрбез. Әбекәй дип торучы, муенына килеп сарылучы күпме оныгы бар бит. Һәр әнигә шундый матур картлык телим.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 232

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+